**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 12 июнендәге 2034 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2026 елның 8 июнендәге 1944 номерлы «Россия – АСЕАН саммитын әзерләү һәм үткәрү вакытында Казан шәһәре урам-юл челтәрендә транспорт чаралары хәрәкәтен чикләү турында»гы карарына үзгәреш кертү хакында**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 маендагы 372 номерлы «Төбәк әһәмиятендәге яки муниципальара, җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне яисә вакытлыча туктатып торуны гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында»гы карары нигезендә **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2026 елның 8 июнендәге 1944 номерлы «Россия – АСЕАН саммитын әзерләү һәм үткәрү вакытында Казан шәһәре урам-юл челтәрендә транспорт чаралары хәрәкәтен чикләү турында»гы карарына, 1 пунктка түбәндәге эчтәлектәге 1.2 пунктчасын өстәп, үзгәреш кертергә:

«1.2. 2026 елның 12 июнендә 00.00 сәгатьтән 2026 елның 20 июнендә 23.59 сәгатькә кадәр Оренбург Тракты урамындагы 95 йорт янында 16:50:171128:173 һәм 16:50:000000:17226 кадастр номерлы җир кишәрлекләрендәге керү юлында һәм парковка зонасында транспорт чараларының, шәхси мобильлек чараларының, курьер хезмәтләренә караган транспорт чараларының һәм заказлар китерүче роботларның туктап торуларын һәм хәрәкәтен чикләүне кертергә».

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.С.Шакировка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**